**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ КАМСКО-УСТЬИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ КАМА ТАМАГЫ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

ул. Калинина, д.31,
пгт. Камское Устье, 422820

Калинин урамы, 31 йорт,
штп. Кама Тамагы, 422820

тел.: (884377) 2-18-85, факс: 2-20-70, e-mail: Kamuste.Ispolkom@tatar.ru, http://kamskoye-ustye.tatarstan.ru.

---

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

22.07.2019 № 597

Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Башкарма комитетының 2017 елның 22 маендагы 535 номерлы карары белән расланган «Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы территориясендә җирләрдән файдалануны һәм җир законнары өлкәсендә хокук бозуларны профилактикалау буенча муниципаль җир контролен (күзәтчелеген) гамәлгә ашыру муниципаль функциясен үтәү» буенча административ регламентына үзгәрешләр кертү турында

«Дәүләт контролен (күзәтчелеген) һәм муниципаль контрольне гамәлгә ашырганда юридик затларның һәм индивидуаль эшкуарларның хокукларын яклау турында» 2008 елның 26 декабрендәге 294-ФЗ номерлы Федераль закон, «Татарстан Республикасы территориясендә муниципаль җир контролен гамәлгә ашыру тәртибе турында» 2015 елның 13 октябрендәге 83-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Башкарма комитетының 2017 елның 22 маендагы 535 номерлы карары белән расланган «Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы территориясендә җирләрдән файдалануны һәм җир законнары өлкәсендә хокук бозуларны профилактикалау буенча муниципаль җир контролен (күзәтчелеген) гамәлгә ашыру» муниципаль функциясен үтәү буенча административ регламенына (алга таба-регламент) регламентның 2.7 пунктын төшереп калдырып үзгәрешләр кертергә.

2. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.

Җитәкче Р.М. Заһидуллин